РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ЮЛБАТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422077, Республика Татарстан,
с. Юлбат, ул. Г.Тукая, 57
тел. (84362) 43-7-22

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЮЛБАТ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422077, Татарстан Республикасы,
Юлбат авылы, Г.Тукай урамы, 57 йорт
тел. (84362) 43-7-22

e-mail: Ulbat.Sab@tatar.ru

19.12.2022 № 23

РЕШЕНИЕ КАРАР

Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 28 нче апрелендә кабул ителгән 11 нче номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә» карарына үзгәрешләр кертү турында

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 17 сентябрендәге 1015 номерлы «Муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, рәис урынбасарлары, аудиторлары, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында" карары нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Советының 28.04.2018 елгы №11 «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә» (09.11.2020 елгы №13, 17.10.2022 елгы №16 Совет карарлары редакциясендә) карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең 12 688 сум күләмендә вазыйфаи окладын раслarга.»;

1.2. Карарның 1 нче кушымтасын 1 нче кушымта итеп яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә»нең 28.04.2018 елгы №11 карарына (Советның 09.11.2018 елгы №26 карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- Нигезләмәнең 2.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Җирлек башлыгына айлык акчалата бүләкләү 0,7717 күләмендә.»;

- Нигезләмәнең 3.5.4 пунктын түбәндәге редакциядән бәян итәргә:

«3.5.4. айлык акчалата кызыксындыру. Муниципаль хезмәткәргә, муниципаль хезмәткәрнең җирле үзидарә органнары структурасы стандартларын элек билгәнгә караганда кечерәк булган муниципаль хезмәт вазыйфасына кертүгә бәйле рәвештә, җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртеп корганда билгеләп куйю очрагыннан тыш, айлык акчалата бүләкләү билгеләнә, анда акчалата бүләкләү күләмен исәпләү муниципаль хезмәткәрнең акчалата тотуын аның элек билгән вазыйфасы буенча акчалата тоту күләменә җиткерүне тәэмин итүне исәпкә алып башкарыла;»

айлык акчалата кызыксындыру. Муниципаль хезмәткәргә, муниципаль хезмәткәрнең җирле үзидарә органнары структурасы стандартларын элек билгәнгә караганда кечерәк булган муниципаль хезмәт вазыйфасына кертүгә бәйле рәвештә, җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртеп корганда билгеләп куйю очрагыннан тыш, вазыйфаи окладының 18 процентыннан артмаган күләмдә айлык кызыксындыру билгеләнә, анда акчалата бүләкләү күләмен исәпләү муниципаль хезмәткәрнең акчалата тотуын аның элек билгән вазыйфасы буенча акчалата тоту күләменә җиткерүне тәэмин итүне исәпкә алып башкарыла;»

- Нигезләмәнең 7.1. пунктның 5) пунктчасында «бер процент» сүзен «18 процент» сүзе белән алыштырырга;

- Нигезләмәнең 8.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8.3. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыкканда, муниципаль хезмәттән киткәндә, тиешле елларны эшләгән өчен пенсия билгеләү озынлыгы муниципаль хезмәт стажы булган очракта, муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча айлык акчалата тотуның биш тапкыр күләмендә бер тапкыр бирелә торган бүләк түбәндәге елларга туры китереп исәпләнә:

- 2020 елда 17 ел,
- 2021 елда 17 ел 6 ай,
- 2022 елда 18 ел,
- 2023 елда 18 ел 6 ай,
- 2024 елда 19 ел,
- 2025 елда 19 ел 6 ай,
- 2026 һәм алдагы еллар 20 ел һәм муниципаль хезмәтнең һәр тулы елы өчен-өстәмә рәвештә 0,5әр, ләкин муниципаль хезмәткәрнең акчалата тотуының уннан артык күләмендә түгел.

Муниципаль хезмәт стажы муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат итү көненнән билгеләнә.»;

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге үзидарә органнарына әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, 2023 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кергән яңа штат расписаниеләрен расларга.

4. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/ulbat адресы буенча урнаштырырга.

Юлбат авыл җирлеге башлыгы Т.Р.Шәмсиев

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Советының 2022 елның 19 декабрендәге 23 номерлы карарына 1 нче кушымта

Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге башлыгының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы акчалата бүләк күләме

| Вазыйфаларның исеме | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Авыл җирлеге башлыгы | 17390 |
| Депутатлар | 12688 |
| Сайланулы вазыйфаи затлар | 12688 |